**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 апрелендәге 1274 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 16 сентябрендәге 3899 номерлы «“2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру” муниципаль программасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын программа максатларына туры китерү һәм программа чараларын гамәлгә ашыру чыгымнарын аныклау максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 16 сентябрендәге 3899 номерлы «“2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру” муниципаль программасын раслау турында»гы карарының 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль программа паспорты» бүлегендә «Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

<table>
<tr><td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме<br>205 676,7 мең сум.<br><br>
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Барлыгы</th><th>Казан шәһәре муниципаль бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>83 238,6</td><td>83 238,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>61 154,6</td><td>61 154,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>61 283,5</td><td>61 283,5</td><td>-</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>205 676,7</td><td>205 676,7</td><td>-</td></tr>
</table>
Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»</td></tr>
</table>

1.2. III бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү**

Программа Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына финанслана. Финанслауның гомуми күләме 205 676,7 мең сум тәшкил итә:

| **Ел** | **Акча күләме, мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Казан шәһәре муниципаль бюджеты** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |
| 2025 | 83 238,6 | 83 238,6 | - |
| 2026 | 61 154,6 | 61 154,6 | - |
| 2027 | 61 283,5 | 61 283,5 | - |
| **БАРЛЫГЫ** | **205 676,7** | **205 676,7** | **-** |

Финанслау күләме фаразлау рәвешендә бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин»;

1.3. «2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.4. Әлеге карарның кушымтасын «2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә

муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының кушымтасы дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 20 апрелендәге
1274 номерлы карарына кушымта

## Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ярдәмче программаларның атамасы | Төп чараларның атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | Чыганагын күрсәтеп, финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2024 база елы | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозуларны профилактикалау, кисәтү, ачыклау һәм булдырмау | Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру | - | Планнан тыш контроль чаралар үткәрү | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2025-2027 еллар | Суд тәртибендә дәгъваланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозуларны төзәтү турында күрсәтмәләр саны | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| | Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту | - | Физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан кылынган административ хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2025-2027 еллар | Казан шәһәрен төзекләндерү өлкәсендә гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча һәм муниципаль норматив хокукый актларның мәҗбүри таләпләрен бозуларның ачыкланган өлеше буенча күрелгән чаралар, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | Идарәнең үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген тәэмин итү. | - | Хезмәткәрләрне һөнәри яктан укыту | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2025-2027 еллар | Өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча квалификация күтәрү үткән хезмәткәрләр саны | 15 | 18 | 17 | 17 | | | |
| **Программа буенча БАРЛЫГЫ – 205 676,7 мең сум** | | | | | | | | | | | **83 238,6** | **61 154,6** | **61 283,5** |